ГОРОДСКОЙ СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
ШӘҺӘР СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

01 июнь, 2018 ел № 25/5

Шәһәр Советының 2013 елның 29 августындагы «Яр Чаллы шәһәрендә социаль найм килешүләре һәм торак урыннарны наймга алу килешүләре буенча наймга алучылар өчен торак урыннан файдаланган өчен түләү (найм өчен түләү), торак урынны карап тоту һәм төзекләндерү өчен түләү күләмен билгеләү тәртибе турында Нигезнамәне раслау хакында» 26/13 санлы Карарын гамәлдән чыккан дип тану турында

Россия Федерациясе Торак кодексының 156 нчы маддәсе, 3 нче өлеше, 2003 елның 06 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ санлы Федераль закон, Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының 2016 елның 26 сентябрендәге «Социаль найм һәм дәүләт, муниципаль торак фондында торак наймы килешүе белән торак бүлмәләрен файдалануга алучылар өчен торактан файдалануга түләү күләмен билгеләүнең методик күрсәтмәләрен раслау хакында» 668/пр санлы приказы, Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмләге Уставының 28 маддәсе нигезендә
Шәһәр Советы

КАРАР бирде:

1. Шәһәр Советының 2013 елның 29 августындагы «Яр Чаллы шәһәрендә социаль найм килешүләре һәм торак урыннарны наймга алу килешүләре буенча наймга алучылар өчен торак урыннан файдаланган өчен түләү (найм өчен түләү), торак урынны карап тоту һәм төзекләндерү өчен түләү күләмен билгеләү тәртибе турында Нигезнамәне раслау хакында» 26/13 санлы Карарын гамәлдән чыккан дип танырга, «Челнинские известия» газетасының 2013 ел, 06 сентябрьдәге 67 нче санында бастырылган.

2. Әлеге Карар үтәлешен тикшереп торуны Шәһәр Советының шәһәр төзелеше, шәһәр инфраструктурасын һәм торак-коммуналь хуҗалыкны үстерү мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Шәһәр Хакиме Н.Г. Мәһдиев

ГОРОДСКОЙ СОВЕТ МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ ШӘҺӘР СОВЕТЫ
ПРОТОКОЛЬНАЯ ЧАСТЬ
БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ